РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Сармановский муниципальный район
Совет
Азалаковского сельского поселения

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Сарман муниципаль районы
Азалак авыл җирлеге
Советы

---

РЕШЕНИЕ
16.12.2025 ел.

КАРАР
№ 13

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Азалак авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

"Муниципаль хезмәт турында" Татарстан Республикасы кодексының 8 статьясына үзгәрешләр кертү хакында 03.10.2025 елгы 66-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Сарман муниципаль районының «Азалак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Азалак авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Сарман муниципаль районы Азалак авыл җирлеге Советының 2022 елның 14 февралендәге 1 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Азалак авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә (Советның 25.11.2022 елгы 52 номерлы, 20.02.2023 елгы 57 номерлы, 05.04.2023 елгы 64 номерлы, 09.08.2023 елгы карарлары редакциясендә) 68, 03.11.2023 N 71, 28.12.2023 N 77, 25.03.2024 N 3, 14.06.2024 N 8, 01.11.2024 N 11, 22.11.2024 N 15) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.5 пунктның 2,3 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен түбәндәге типик квалификация таләпләре билгеләнә:

1).һөнәри белем дәрәҗәсенә карата: югары белем булу - вазыйфаларның югары, баш һәм әйдәп баручы төркемнәре өчен, авыл җирлекләре җирле үзидарә органнарындагы вазыйфаларның югары, баш һәм әйдәп баручы төркемнәре өчен; югары белем яки урта һөнәри белем булу - авыл җирлекләре җирле үзидарә органнарындагы вазыйфаларның югары, баш һәм әйдәп баручы төркемнәре өчен, шулай ук вазыйфаларның өлкән һәм кече төркемнәре өчен;

2) муниципаль хезмәт стажына яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эш стажына:

муниципаль хезмәтнең югары вазыйфалары буенча-кимендә бер ел муниципаль хезмәт стажы яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча кимендә ике ел эш стажы;

муниципаль хезмәтнең төп вазыйфалары буенча-муниципаль хезмәт яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча кимендә бер ел эш стажы.".

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Председатель Совета Азалаковского сельского поселения Сармановского муниципального района И.Г.Габдулгазизов